Мексика егетләре Россия җыелмасын елатты

Конфедерацияләр Кубогында «А» төркемендә ярымфиналга чыккан командалар билгеле булды: 28 июнь көнне «Казан-Арена» стадионы Португалия белән Чили футболчыларын каршы алачак. Безнекеләр исә шимбә көнне мексикалыларга 1:2 исәбе белән оттырды.

8 БИТ

Газетага язылу 2017 елның 29 июненә кадәр дәвам итә

ИНДЕКСЛАР

П2430 – пәнҗешәмбе саны, ярты елга язылу бәясе – **450 сум.**

П2395 – атнага өч тапкыр: сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга көннәрендә чыга, ярты елга язылу бәясе – **930 сум.**

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри Казан

татмедиа

Сишәмбе | 27.06.2017 | №68 (5830)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

САБАН ТУЕ КӨРӘШ КЕНӘ ТҮГЕЛ, УЛ – ТАТАРНЫҢ МӘҢГЕ ЯШӘВЕ

МИЛЛИ-МӘДӘНИ МИРАС

Татар халкының милли бәйрәме – Сабан туе, гадәттә, язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелә. Быел Рамазан ае июньгә туры килгәнлектән, бәйрәм беркадәр кичектерелде. Республика авылларында һәм шәһәрләрендә Сабан туйлары – 1-2 июльдә, Казанда 15 июльдә үткәрелә.

Дамир БӘДРИЕВ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Татарстан башкаласында Сабан туе Тынычлык бистәсе янәшәсендәге Каенлыкта һәм «Казан» халыкара ат-спорт комплексында оештырыла.

Каенлыктагы Сабан туе иртәнге якта 10.00 сәгатьтә башлана. Кунакларны республиканың 11 муниципаль районының мул һәм күңелле «ишегаллары» каршылый. Үзешчән сәнгать коллективлары чыгыш ясый. Төп мәйданда театраль тамаша 11.00 сәгатьтә башлана. Аннан соң мәйдан түренә көрәшчеләр чыга. Матур йола буенча, баш батырга тәкә әзерләп куелган. Тәкәнең мөгезенә бүләккә дигән автомобиль бәйләнәчәк.

Шәһәр Башкарма комитетының мәдәният идарәсе җитәкчесе Азат Абзалов сөйләгәнчә, көрәш белән беррәттән төп мәйдандагы сәхнәдә Татарстанның сәнгать осталары чыгыш ясаячак. Аланнардагы кече сәхнәләр Казан районнары үзешчән артистлары карамагында булачак. Мәйданчыкларда теләге булган һәр кеше гер күтәрү, туры яки авыш баганага менү, «капчык белән сугышу», капчык киеп йөгерү, кашыкка йомырка салып йөгерү, аркан яки таяк тартышу, чиләк-көянтә белән су ташу һәм башка уен-бәйгеләрдә катнаша алачак. Сабан туеннан бүләк белән кайту – үзенә бер күңелле.

Бәйрәм программасы кичке якта «Казан» ат-спорт комплексында дәвам итә. Биредә ат чабышлары һәм татар эстрадасы йолдызлары катнашында концерт булачак. Җәйге кафелар эшләячәк. Милли ризыклар да мулдан булачак. Сәүдә рәтләрендә халык һөнәрчеләре үзләре җитештергән сувенирларны, товарларны тәкъдим итәчәк.

Тынычлык бистәсендәге Каенлыкка автобуслар 8.00 сәгатьтә «39нчы квартал», «10нчы микрорайон», «Җиңү проспекты» метро станциясе, «Филармониянең концертлар залы», «Оренбург тракты урамы», «Глазунов урамы» тукталышларыннан йөри башлый. Билет бәясе – 25 сум. Автобуслар Сабан туе мәйданыннан барча кешене алып кайтып бетергәнче йөриячәк.

Сабан туе көнендә, ягъни 15 июльдә 6.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр Ферма шоссесы җәяүлеләр карамагында булачак. Каенлыктагы мәйданга бару юнәлешендә автомобиль юлы Оренбург тракты урамыннан башлап бер генә як хәрәкәтле итеп калдырыла. Ферма шоссесында Яңа-Дәүләки урамыннан Гәрәев урамына кадәрге өлештә транспорт чараларын кую чикләнә.

Кирам САТИЕВ, Татарстанның халык артисты:

– Мин – музыкант кеше. Бала чактан ук, әле музыкант булганчы, Сабан туйларына гармун күтәреп чыктым. Уйнадым, Сабан туйларында гармунда һәм баянда 53 ел уйныйм икән инде. Милләтемнең, халыкларның күңелен күтәрер өчен эшлим мин моны. Казахстанда Сабан туенда булдым инде, 1 июльдә Бакудагы Сабан туена барабыз. Сабан туйлары хәзер халыкара дәрәҗәдә үткәрелә. Татар халкының милли бәйрәме – Сабан туе халыкларны дуслаштыру, берләштерү символына әверелде.

Илсөяр ИКСАНОВА, шагыйрә, «Түгәрәк уен журналының баш мөхәррире.

– Сабан туе элек-электән халыкка талантын-сәләтен, көчен-гайрәтен күрсәтер мәйдан иде. Ә хәзер ул читтән килгән артист-җырчыларның акча эшләү урынына гына әйләнеп бара. Аның электән килгән асылын саклыйсы иде.

«Казаннан Иссык-Күлгә авиарейслар ачарга кирәк»

Россиягә алты көнлек эшлекле сәфәре кысаларында, Кыргызстан Республикасы Президенты Алмазбәк Атамбаев Казанда да булды. Ул Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов белән очрашты. Җитәкчеләр ике республика арасындагы уртак хезмәттәшлек турында фикер алышты.

tatarstan.ru

Татарстан белән Кыргызстанны бәйләүче сәбәпләр җитәрлек. Алмазбәк Атамбаевның хатыны Рәисә Атамбаеваның милләте буенча татар булуы – шуларның берсе генә. Татарстан югары уку йортларында Кыргызстаннан 244 студент белем ала. Мәдәният өлкәсендә дә уртак проектлар җитәрлек. Ике республиканы язучы Чыңгыз Айтматов та бәйләп тора. Сүз уңаеннан, киләсе елга язучының тууына 90 ел тулуга багышланган чараларны Татарстанда да, Кыргызстанда да билгеләп үтәчәкләр.

– Чыңгыз Айтматов, әлбәттә, кыргыз халкының мәшһүр улы, әмма анда татар халкының да өлеше бар. Без ел саен уздырыла торган «Айтматов укулары»нда катнашырга сөйләштек, – ди Рөстәм Миңнеханов.

Сәфәр барышында Алмазбәк Атамбаев «Яңарыш» фондының җидееллык эшчәнлеге, тарихи-мәдәни мирасны саклау буенча башкарылган эшләр белән танышты. Кыргызстан өчен дә тарихи-мәдәни һәйкәлләрне саклау – иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора икән. Җитәкчеләр Болгар ислам академиясе төзелеше һәм Казан Изге Ана иконасы Соборын торгызу турында да сөйләштеләр. Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Президентны борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчегенә кунакка чакырды. Алмазбәк Атамбаев исә быел көз көне килергә вәгъдә бирде. Кунак ашы – кара-каршы дигәндәй, Кыргызстан Президенты үз чиратында Татарстан делегациясен үзләрендә узачак халыкара форумда күтеп калуын әйтте.

Туризм өлкәсендә дә уртак проектлар каралды. Киләчәктә Казан – Иссык-Күл – Казан авиарейсын булдыру идеясе дә бар.

– Кыргыз авиакомпаниясе Бишкәк – Казан – Бишкәк рейсын башлап җибәрде. Казан авиакомпаниясенең дә Казан – Иссык-Күл – Казан рейсын булдыруы кирәк. Иссык-Күлдә халыкара аэропорт бар. Анда Гарәп илләренә яки Төркиягә караганда күпкә иминрәк. Бер менталитет, бер рус теле, ул да бездә рәсми тел булып тора. Авиарейсны бу сезонда ук, җәйге чорда булса да, башлап җибәрергә кирәк, – диде Алмазбәк Атамбаев.

Иссык-Күл – Кыргызстанда иң зур күл. Ул мәйданы буенча дөньяның иң зур 25 күле исемлегенә кергән. Баксаң, Иссык-Күл тирәсендә коттеджлар салу популярлаша бара икән. «Йорт алырга теләгән татарстанлылар ашыксыннар», – дип тә уенын-чынын бергә кушып өстәде Кыргызстан Президенты.

Күпләрне борчыган мәсьәлә – Кыргызстанда хезмәт итүче егетләрне Сүриягә җибәрәләр икән, диган имешмимешләргә дә Алмазбәк Атамбаев нокта куйды.

– Утырышларда, Владимир Путин белән кичке аш вакытында да әлеге мәсьәләнең күтәрелгәне булмады. Бу хакта сүз чыккан очракта да, беренчедән, коллектив куркынычсызлык турында килешү оешмасы (ОДКБ) вәкилләренең бердәм карары, икенчедән, Берләшкән Милләтләр оешмасы резолюциясе кирәк. Өстәвенә, барысын да парламент хәл итәчәк, – диде Президент.

Очрашуда машина төзелеше, авиатөзелеш, химия һәм ягулык-энергетика өлкәсендәге уртак хезмәттәшлек каралды. «Кызганычка, хәзер без булган потенциалны тулысынча кулланмыйбыз. Безгә икътисади өлкәдә сәүдә хезмәттәшлеген көчәйтергә кирәк», – дип билгеләп үтте Рөстәм Миңнеханов.

Кыргызстан белән Татарстан арасында туганнарча җылы мөнәсәбәтләр күптән урнашкан, ә шулай да Кыргызстан Президентының безнең республикага беренче генә сәфәре икән. Хәер, соңгысы булмас кебек.

– Без барлык тармакларда диярлек уртак чаралар турында сөйләштек: икътисад һәм мәдәният, хәтта тарих. Минемчә, бу – нәтиҗәле сәфәр, – дип билгеләп үтте Алмазбәк Атамбаев.

Ике республиканың киләсе очрашуы Бишкәк шәһәрендә булачак. 20-22 июльдә анда «Алтай цивилизациясе һәм алтай телләре гаиләсеннән булган тугандаш халыклар» халыкара форумы узачак.

– Ахыр чиктә, без барыбыз да Алтайдан чыккан. Кыргызстанда үтәчәк бу мөһим чарада, без, әлбәттә, катнашачакбыз, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Фатирлар «Салават күпере»ндә генә төзеләчәк

«Салават күпере» микрорайонында социаль ипотека программасы буенча фатир отучылар, канәгатьсезлек белдереп, 19 июньнән чатырларда яшәүгә күчкәннәр иде. Торак комплексыннан ерак түгел, алар 14 палатка урнаштырганнар. Дәүләт торак фондының башкаручы директоры Тәлгать Абдуллин аларның хәлен белде. «Татар-информ»да узган матбугат конференциясе дә социаль ипотека программасындагы яңалыклар, фатирларның сыйфатына багышланган иде.

Республикада социаль ипотека программасы буенча 10 меңнән артык кеше чиратта тора. Аларның 6 меңе Казаннан фатир алырга өметләнә. Социаль ипотека программасы эшли башлаганнан бирле, барлыгы 95 меңнән артык кеше фатирлы булган.

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Чатырларда яшәүчеләрнең күбесе төзүчеләрнең, подрядчы оешмаларның яхшырак эшләвен таләп итә икән.

– Тик кичләрен пылау пешереп, чатырда яшәгәнче, эшчеләрне ашатсыннар, яхшырак эшләрләр. Нәрсәдер булдырырга телибез икән – бүлешеп, табышланып йөрүдән файда юк. Әгәр дә алар төзелеш тәмамлануны, проблемаларны хәл итәргә тели икән, башка юл эзләсеннәр, – ди Тәлгать Абдуллин.

Барысын да юридик юл белән хәл итәргә була дип саный җитәкче. Фатир отучының биш ел дәвамында йортның сыйфаты буенча шикаять белдерергә хакы бар. Иң яхшысы – фатир ачкычларын алганчы, торакны кабул итү актына кул куйганчы ук сыйфаты канәгатьләндермәгән урыннарны күрсәтү. Күзгә күренми торган кимчелекләр турында сүз барганда, барысын да суд аша хәл итәргә була.

– Кимчелекне күрсәтеп, гарыза тапшырырга, таләпләрне язарга кирәк. Аны генераль подрядчылар, идарәче компания, эксплуатациягә тапшыру бүлеге хезмәткәрләре дә карый. Чынлап та кимчелек барлыгы ачыкланса, подрядчы үз гаебен таныса, хатаны тиз арада төзәтәчәкләр. Әгәр подрядчы килешмәсә, эш судта хәл ителә. Бу озаграк вакыт таләп итә. Әмма биш ел вакыт узганнан соң, бар җаваплылык та йорт милекчесе өстендә, – ди Тәлгать Абдуллин.

Ничек кенә булмасын, социаль ипотека программасында чиратта торучыларның башка юлы юк кебек. Фатир булганны сабыр гына көтәргә туры килә. Торак көтү вакыты – элеккечә, өч ел. Дөрес, бу вакыт озагракка сузылырга да мөмкин, чөнки йортның проектын төзү өчен генә дә ике еллап вакыт таләп ителә икән.

Тагын бер яңалык – киләчәктә социаль ипотека программасы буенча фатир алганда әллә ни сайлау мөмкинлеге булмаячак.

– Киләчәктә социаль ипотека программасы буенча барлык йортлар да «Салават күпере» торак комплексында төзеләчәк. Киләсе елга 7, 8нче микрорайоннарны төзеп бетерергә тиешләр. Барлыгы 250 мең квадрат метр торак файдалануга тапшырылачак, – ди Тәлгать Абдуллин.

«Салават күпере» торак комплексында барлыгы 55 мең кеше яшәр дип көтелә. Бүген социаль ипотека программасы буенча бирелә торган фатирның квадрат метры 40 мең сумга кадәр җитә.

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НДӘ ПЕДИАТР ОФИСЫ АЧЫЛАЧАК

«Салават күпере» торак комплексында быел педиатр офисы ачылачак. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов карары белән гамәлгә керәчәк әлеге офис 300 квадрат метр мәйданда урнашыр дип көтелә.

– Моңа охшаш проект Юдино бистәсендә дә эшли. Татарстан Дәүләт торак фонды биргән бинада сырхауханә урнаштырдык, хәзер ул уңышлы гына эшләп килә. «Салават күпере» торак комплексында ачылачак педиатр офисы да шул системага корылган. Офис өчен бина инде әзер. Президент карары да бар. Дәүләт торак фонды белән берлектә эчке эшләрне тәгәлләп, офисны җиһазлар белән тәэмин итеп, эшне башларбыз дип уйлыйм. Безнең өчен иң мөһиме – торак комплексы төзелгәндә, анда медицина ярдәме алу өчен мөмкинлекләрнең тудырылган булуы, – диде Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин.

БҮЛӘККӘ – ГАЗЕТА

РФ Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллин һәм сәламәтлек саклау министры Адел Вафин «Игелек территориясе» хәйрия акциясенә кушылдылар. Күп балалы һәм аз керемле 11 гаиләгә алты ай буе Айрат Фәррахов бүләк иткән «Шәһри Казан» газетасын укый алачак.

– Бик күпләр кебек, мин дә яңалыкларны күбрәк гаджетлар ярдәмендә алам. Интернет революциясе басма газеталарга зур көндәш булып тора. Бу – закончалык, дөнья үсештә. Шулай да мин басма газета-журналлар юкка чыгар дип уйламыйм. Кофе эчеп, битләрен актара-актара газета укуның үз рәхәте – ди Айрат Фәррахов.

Адел Вафин исә ярты еллык подписканы Әлки, Саба, Тукай районнарындагы интернат-йортларга, Апас, Балтач, Әгерҗе районнарындагы тернәкләндерү үзәкләренә бүләк итте. Радик Гайзатуллин, бүләк ясап, ун гаиләне сөендерде.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

СӘЛАМӘТЛЕК

Төзүчеләрне Президент сырхауханәләргә җибәрде

Казанда быел 53 сырхауханә (поликлиника) бинасын капиталь төзекләндерү башлана.

– Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов башлангычында торак йортларны, ишегалларын капиталь төзекләндерү бара. Моңа мәктәпләр һәм балалар бакчалары кушылды. Президент теләктәшлегендә, сырхауханәләрне капиталь төзекләндерергә керешәбез. Бу гаять әһәмиятле программа, Казанда 53 бина яңартылачак, бу бик зур сан, – диде башкала мэры Илсур Метшин кичә «эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә.

Быел Казандагы сырхауханәләрне төзекләндерүгә 1 миллиард 348 миллион сумнан артык акча тәгаенләнгән.

– Казанда халыкка медицина хезмәте күрсәтүдә күп эшләр гамәлгә ашырыла, ләкин казанлылардан, 2016 елдан башлап, медицина хезмәтенә канәгатьсезлек белдереп, «халык контроле»нә мөрәҗәгать итүләр күбәйде, – дип әйтеп үтте үзенең докладында шәһәрнең сәламәтлек саклау идарәсе җитәкчесе Илнур Хәлфиев.

Төзекләндерү программасына шәһәрнең 10нчы, 20нче һәм 18нче сырхауханәләре дә алынган. Биналарны төзекләндерү белән беррәттән тышкы мәйдан да тәртипкә китерелә, автомобиль куеп тору урыннары булдырыла.

Яңа Савин белән Киров районнарында балалар өчен сырхауханә төзүгә керешелә. Киров районының Октябрьгә 25 ел урамындагы сырхауханә бинасы төзелүгә инде 80 ел тулган. Бу бина сүтелеп, яңадан төзелә.

– Медицина аппаратуралары да яңартылачак. Беренче чиратта йөрәк, яман шеш авыруларын ачыклый торган аппаратуралар сатып алыначак, – диде Илнур Хәлфиев.

Көн тәртибенә куелган мәсьәләгә йомгак ясап, мэр Илсур Метшин биналарны төзекләндерүне һәм җиһазландыруны «медицинада алга адым» дип бәяләде.

Дамир БӘДРИЕВ.

Сәүдәгә футбол ярдәм итә

Татарстанның сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары Альберт Кәримов сүзләренчә, Конфедерацияләр Кубогы Татарстан икътисады үсеше өчен зур этәргеч булачак.

– Биредә бер көнлек керем турында гына сүз бармый. Дөньякүләм спорт чаралары – уңышка китерүче юл. Кубок барган көннәрдә меңләгән чит ил кешесе Казанда кунак булды. Үзләренә безнең шәһәр турында бары уңай тәэсирләр белән генә кайтып китәләр. Футбол бәйрәме безгә күбрәк дөнья дәрәҗәсендә Казан йөзен күрсәтү өчен мөһим. Узган ел нәтиҗәләре буенча, республикада ваклап сату товар әйләнеше артмады, бу чара нәкъ менә шуны үстерер дип уйлыйм. Казанга, Татарстанга килгән туристлар агымы да бермә-бер артачак, – диде министр урынбасары.

БЕЛЕП ТОР!

Юридик хезмәт бушлай күрсәтелә

Быелның 30 июнендә халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтү буенча Бөтенроссия көне үткәрелә.

Татарстан Республикасында юридик белешмәләрне Россия Федерациясе Президентының Татарстандагы кабул итү бүлмәсендә, «Бердәм Россия» партиясе рәисенең төбәк җәмәгатьчелек кабул итү бүлмәсендә, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының кабул итү бүлмәсендә, «Бердәм Россия» партиясенең районнар (шәһәрләр) бүлекләре җәмәгатьчелек кабул итү бүлмәләрендә, Россия юристлары ассоциациясенең Татарстан төбәк бүлегенең халыкка бушлай юридик ярдәм күрсәтү үзәкләрендә, Әлмәттә һәм Бөгелмәдә, гомумән 56 үзәктә үткәрелә.

Казанда җәмәгатьчелекне кабул итү – 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә, ә районнарда һәм башка шәһәрләрдә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр бара.

КАЗАНДАГЫ АДРЕС:

Россия Федерациясе Президентының Татарстан Республикасындагы кабул итү бүлмәсе – Кремль урамы, 12/20; тел. **221-80-36.**

«Бердәм Россия» партиясе рәисенең төбәк җәмәгатьчелекне кабул итү бүлмәсе – Карл Маркс урамы, 31/7. Кабул итү 10.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр; тел.**238-10-00.**

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының бушлай юридик ярдәм күрсәтү үзәге – Батурин урамы, 7, беренче каттагы 136нчы бүлмә; тел. **567-80-97.**

«Бердәм Россия» партиясенең районнар бүлекләре адресларын Россия юристлары ассоциациясенең Татарстан төбәк бүлегенең сайтыннан карарга мөмкин: **alrf16.ru.**

«Терлек азыгы әзерләүдә кыенлыклар бар»

Авыл хуҗалыгы тармагы терлек азыгы әзерләүдә кыенлыклар кичерә. Журналистлар белән очрашу вакытында Татарстанның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Илдус Габдрахманов әнә шулай дип белдерде. Аның сүзләре буенча, башка елларны бу вакытта печән һәм сенаж биш тапкырга күбрәк әзерләнгән булган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Узган ел без беренче мең тонна печәнне 23 майда ук әзерләгән идек. Быел июнь ахырына да печән юк дәрәҗәсендә. Сенаж әзерләү дә авырлык белән бара. Моның өчен хуҗалык җитәкчеләрен ачулану дөрес булмас иде, әлбәттә. Алар да сенажга бик юеш массаны куя алмый бит инде. Шук ук вакытта һава торышының яхшырганын көтеп ятудан да мәгънә юк. Үсемлек үсә һәм картая башлый, димәк, азыкның сыйфаты да начарлана. Шуңа күрә без массаны мәҗбүри консервантлар кулланып куярга киңәш итәбез, – диде ул.

Шуннан соң җитәкче чәчү эшләренең уңышлы тәмамлануы турында кабат искә төшерде. Чәчүлек мәйданнары, алдагы еллардагы кебек үк, 2 млн 900 мең гектарны тәшкил итә. Алдагы еллар белән чагыштырганда, быел чәчү кампаниясе сыйфатлырак һәм оешкан төстә узган. Моңа, беренчедән, һава шартлары, икенчедән, минераль ашламаларны кирәкле дәрәҗәдә кертү уңай йогынты ясаган. Яз озак сузылуга карамастан, чәчү кампаниясе сыйфатлы һәм вакытында башкарылган.

– Башка елларны, гадәттә, яз булмыйча, кыштан тиз генә җәйгә күчеш була торган иде. Бу исә темпның сыйфатына тәэсир итте. Быел туфракны сыйфатлы әзерли алдык, кирәкле бөтен чараларны да башкардык, – диде ул.

Хәзерге вакытта чәчүлекләрне тәрбияләү эшләре бара. Яңгырның күп явуы аркасында килеп туган проблемалар да бар. Дымлы һава торышы чүп үләннәренең һәм авыруларның артуына китергән. Шулай да саклагыч чаралар кулланганда, уҗымнар яхшы булыр дип саный җитәкче.

Илдус Габдрахманов әйтүенчә, быел шикәр чөгендере мәйданнары арттырылган. Узган ел 64 мең гектар булса, быел 74 мең гектарга чәчелгән.

– Шикәр чөгендеренең уңышы яхшы булыр дип өметләнәбез. Аннан соң әлеге культураларны үстерү белән профессионаллар шөгыльләнә, чөнки бу күп чыгымнар таләп итә, – диде ул.

РОССИЯДӘ КЫР КӨНЕ

Сигез еллап тәнәфестән соң, Россиядә кабаттан кыр көне уздырылачак. Россия масштабында уза торган чара 5-7 июль көннәрендә булачак.

– Аграр тармакта эшләүче кешеләр өчен бу бик мөһим чара. Моңа без яхшылап әзерләндек. Көздән үк әзерләгән кырлар яхшы хәлдә. Игенчелек буенча – 34, ә Россия субъектларыннан барлыгы 165 компания катнашачак. Шулай ук чит ил компанияләре дә бар, – диде җитәкче.

«Журналист буласым килә»

Кичә – 26 июнь көнне, XXII Республикакүләм «Алтын каләм» балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугаты фестивале ачылды. Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыргач, булачак журналистлар ел саен шулай каләм көчен сынарга җыела. Бүләге дә саллы гына – Казан федераль университетының Журналистика һәм медиакоммуникацияләр югары мәктәбенә конкурссыз гына укырга керү.

Алисә САБИРОВА

Яшьләр биш көн дәвамында татар, рус журналистикасы, телевидение, радио, фото, PR, версткалау кебек юнәлешләр буенча белем туплый, иҗат итә. Журналистлар арасында шундый сынамыш та бар: «Алтын каләм»дә үзен сынап караган кеше, Гран-при алмаса да, бу өлкәдә, һичшиксез, уңыш казаначак. Биредә алар журналист-остазларыннан гамәли һәм теоретик дәресләр ала.

Фестивальдә катнашу өчен балалар, беренче эш итеп, еллар дәвамында тупланган иҗат эшләрен тапшыра. Әйтик, Резидә Әлмиева биредә инде дүртенче тапкыр килә икән. Шушы вакыт эчендә ул үзен корреспондент, версткалаучы, фотограф буларак сынарга өлгергән.

– Журналистика ул – шулкадәр киңкырлы хезмәт. Аның һәр өлкәсендә үземне сынап карыйсым килде. Берничә ел элек татар журналистикасында перспектива бетте кебек тоелган иде. Татар кафедралары ябыла дигән сүз дә чыкты. Бәлкем шуңа да фото төшерергә алынганмындыр. Элек мин, журналистика – иншалар язу, дип кенә уйлый идем. «Алтын каләм»дә моның бары тик миф икәнен аңладым. Безнең эш фактлардан торырга тиеш. Фестивальдә дүрт ел катнашу дәверендә журналистикага карашым 180 градуска үзгәрде. Киләчәктә үземне татар интернет басмасында эшләүче журналист буларак күрәм. – ди IX сыйныф укучысы.

Резидә бүген – «Ялкын» журналының балалар редколлегиясе әгъзасы. «Сабантуй» журналында һәм үзләренең район газетасында даими автор.

Башка еллардан аермалы буларак, быел катнашучылар рус басмасы («Казанские ведомости»), татар басмасы (Арча районы, Кырлай авылы), телевидение («Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе), PR («Brainstore agency» креатив һәм коммуникация агентлыгы), фотохәбәрче («Видимый свет» иҗат студиясе), версткалаучы (типография) юнәлешләре буенча эшлекле командировкага да барачак әле. Бу исә журналист казанының ничек кайнавын күрү, матбугатның эчке кухнясы белән танышу дигән сүз.

Ачылыш тантанасында Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова булачак хезмәттәшләрен сәламләде.

– Фестивальнең 22нче ел баруына ышанасы да килми. Журналист – бик җаваплы һөнәр. Ул – хакимият белән халык арасында күпер салучы. Йокысыз төннәргә әзер булыгыз, мендәр кочаклап ятарга вакыт булмаячак. Программагыз бик тыгыз. Үзегезне кызганмагыз, мин сезгә җиңү телим! Сезнең өчен бу биш көн – вузга укырга керү өчен зур әзерлек булачак, – диде Римма Ратникова.

Быел фестивальдә 130 кеше катнаша, шуларның 32се – татар журналистикасы юнәлеше буенча килүчеләр.

ФӘН

Автор фотосы

Татар тарихы әле «җир астында»

Татарстанның көньяк-көнчыгыш районнары моңа кадәр табигый казылмалары белән дан тота иде. Бу төбәкнең тарих «казылмаларына» да бик бай булуы ачыкланды.

– Татарстанның көньяк-көнчыгышына 2009 елдан башлап фәнни экспедицияләр үткәрергә керештек. Азнакайда фәнни-гамәли конференция оештырылды. Чирмешән, Бөгелмә, Ютазы, Сарман, Әлмәт, Лениногорск районнары җирлекләрендә татарларга кагылышлы борынгы тарих өйрәнелмәгән әле. Казан зонасындагы кебек үк биредә дә әһәмиятле тарих «җир астында» ята, – диде галим, тарихчы-археолог Альберт Борһанов кичә «Татар-информ» агентлыгында үткәрелгән матбугат конференциясендә.

Тарихчы-этнограф Дамир Исхаков, әйтүенчә, 1,5 миллион татар исәпләнгән күрше Башкортстанда да татарларга кагылышлы тарих аз өйрәнелгән.

Башкортстанда башкортларның тарихын барлау, тарихи китаплар чыгару дәүләт югарылыгында башкарыла икән. Безнең галимнәр, Татарстанда да татар тарихын өйрәнүгә дәүләт тарафыннан зуррак игътибар бирелсен иде, дигән теләкләрен җиткерделәр.

Дамир БӘДРИЕВ.

ПОЧТАДАН

Әлфия апаны сагынырбыз әле

Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әлфия Авзалованың арабыздан китүе барыбыз өчен дә зур югалту булды.

…Мәгълүм ки, Әлфия апа биш яшеннән әнисез кала, әтисе Афзал Бөек Ватан сугышында һәлак була. Безнең авылда Әлфия апа белән бер үк балалар йортында тәрбияләнгән Актаныш кызы Рауза Зарипова-Бәхтиярова яшәде. Бөек Ватан сугышыннан соң бу гаилә Актаныштан безгә – Чувашстанның Козловка районы Әлмән авылына күченә. Рауза белән Әлфия бер сыйныфта бер парта артында утырып белем ала. Рауза апаның сеңелләре Сания белән Равилә дә булачак җырчы белән дус булалар.

Узган гасырның 70нче елларында Рауза апа Әлфия Авзалованың концерты вакытында Казанда очрашалар. Ахирәт дуслар кочаклашып елашалар. Шул очрашу вакытында җырчы: «Мин сезнең авылга кайтам әле бер», – ди. «Ул чагында авыл халкы: «Әлфия Авзалова кайта икән», – дип бик көтте. Кызганыч, без аны никадәрле генә көтсәк тә, легендар җырчыбыз кайта алмады», – дип сөйләгәне истә Рауза апаның.

Әйтергә кирәк, ул үзе дә бик матур җырлый иде. Казанда, Чабаксарда яшәүче кызлары Сания, Дания, Рузәлия һәм Рушания да моңлылар. Алар да Әлфия апаның җырларын тыңлап үскән кызлар. Хәер, «Актаныш таңнары», «Әниемнең җылы кочагы», «Ак чәчәкләр кебек кар ява»ларны кем генә белми соң?!

Равилә МӨБАРӘКШИНА,
Казан.

Чын егетләр эше

Бу көннәрдә башкалабыз полиция идарәсе хезмәткәрләренең эше аеруча тыгыз. Конфедерацияләр Кубогы кысаларында узучы футбол уеннарының тәртипле үтүен тәэмин итәргә тиеш алар. Махсус форма кигән кызу торучы патрульләрнең шәһәр урамнарында ешрак күренүе шуның белән бәйле.

Дөрес, шәһәр идарәсенең полиция участогы инспекторлары (халыкча әйтсәк, участковыйлар) мондый тынгысызлыкка әллә ни аптырамыйлар. Башка көннәрдәге эш киеренкелеге дә бүгенгесеннән ким түгел, диләр. Әйтик, 3нче «Елга арты» полиция участогында бүлек җитәкчесе майор Рөстәм Хаялиев бу көннәрдәге мәшәкатьләрен болай аңлатты:

– Әлеге футбол чемпионаты казанлылар өчен үзенә бер төрле спорт бәйрәме инде ул. Андый җыеннарда тәртип саклау өчен полиция идарәсе үткәрә торган махсус чараларда без дә катнашабыз, әлбәттә. Әмма бәйрәм килә дә гөрләп үтеп тә китә. Көндәлек хокук саклау эшләрендә дә йомшаклык күрсәтергә ярамый. Хокук сагында торучы егетләрнең – участок инспекторларын күздә тотам – сирәгәймәвен халык һәм аеруча кырын эшкә шомарганнар күреп-белеп торсыннар. Хәзер без ишегалларында торган иске машиналарны барлап чыгарга керешәбез. Искегә кем тисен дип уйлаган беркатлы хуҗасы айлар буе якын килмәгән машиналарны һәр ишегалдында күрергә мөмкин. Аларның хуҗаларын табып кисәтергә кирәк. Сакка куйсыннар. Югыйсә, каракларның кулга төшерүләре бар. Районда ниндидер «эшмәкәрләр» шундый онытылган машиналарга күз салган икән, кеше әйберен тимер-томырга тапшырып, тиз генә акча юнәтмәкче болар. Әгәр без кичектергесез чара күрмәсәк, бу кырын эш йогышлы чир кебек таралачак.

Полиция идарәсенең 3нче «Елга арты» бүлеге участок инспекторлары бүлеге башлыгы полиция майоры Рөстәм Хаялиев белән мин менә шундый кызу эш арасында очраштым.

Кала тынычлыгы участокларда хокук бозуларга чик куючы инспекторлар тырышлыгы белән тудырылуы яхшы мәгълүм. Эшләре күп аларның. 22 участок инспекторы һәм җиде балигъ булмаган яшүсмерләр белән эшләүче инспектордан торган бүлек хезмәт күрсәткән мәйданда 370 күп фатирлы торак йорт, 1500 шәхси өй һәм сигез бакчачылык ширкәте керә.

Инде җитәкченең үзе белән дә танышыйк. Рөстәм Илдус улы инде тугыз ел участок инспекторы булып эшли. Ике югары белемгә ия: башта Казан педагогия институтын тәмамлап, математика укытучысы дипломын ала, аннары Казан юристлар институтын тәмамлап, югары белемле юрист була. Үзе әйтүенчә, полиция хезмәтенә яшьли кереп чарлансада да, аның эшендә педагоглык, ягъни кешене тәрбияләү өстенлек ала. Майор аны үзенчә кисәтү-профилактика чарасы дип атый.

– Безнең төп бурыч – хокук бозуны, җинаятьне булдырмау. Менә шуннан килеп чыга да инде алдан кисәтү зарурлыгы. Кеше беренче тапкыр юлдан тайпыла икән, аңа тагын шулай дәвам итсә нәрсә көтәчәген ныклап аңлатырга кирәк. Әгәр соңарсак, җәзасыз котылырга мөмкин икән дигән ялгыш фикер ныгып урнашуы бар. Ә инде ныклап аңлаткач, күп очракта нәтиҗә уңай була. Беркемнең дә ирекне төрмәгә алыштырасы килми. Әйтик, иң киң таралган җәнҗал – гаилә эзгышын алыйк. Ул бит күбесенчә исереклəр арасында килеп чыга. Аек кеше талашса да чыгырдан чыкмый, тыктый белә. Эчкечелек – төп бәла. Араки белән мавыкканны алдан айныттырга, эчмәскә өндәргә кирәк. Бусы иң авыры, шуңа күрә һәр опорный пунктта җәмәгать советы оештырылган. Аның составына район хакимияте белгече, торак йорт коммуналь хуҗалыгы вәкиле һәм участок инспекторы керә. Чын-чынлап тотынгач, җәмәгатьчелек тырышлыгы белән, кешене акылга утыртырга була.

– Хәзерге вакытта сезнең участокта кисәтелгән кешеләр күпме?

– Безнең бүлектә 1100 кеше исәптә тора. Алар белән даими эш алып барыла.

– Үзәккә үткән берәр очракны искә төшерсәк...

– Әлеге дә баягы эчкечелек тәмам теңкәгә тия. Аның аерым очрагын сөйләүдән мәгънә юк. Алда әйткән исәптә торучыларның күбесе исерек килеш ахмаклык кылган бит. Эчкечене айныту бик кыен. Мөгаен, безнең районның иң зур бәласедер дә әле ул. Күргәнегезчә, мондагы халык узган гасырның 70нче елларында ук төзелгән иске йортларда яши. Кешечә рәхәт яшәргә кызыга алар да. Телевизор күрсәтеп тора бит матур торакларны, уңайлы яшәү шартларын. Ә моңа ирешү өчен акча кирәк. Менә шул проблеманы хәл иткәндә, ялгышлыклар ясала да инде. Бернәрсә дә барып чыкмагач, күбесе кайгыдан аракыга тотына.

– Турысын әйтик, әшегез күңелле түгел. Югары белемле педагог Рөстәм Хаялиев ни өчен бу мәшәкатьле эшне сайлады икән?

– Институтны тәмамлагач ук мин милициягә эшкә кердем, участок инспекторы булып. Мине, шунда бар, дип, беркем дә димләмәде, үзем сайладым. Мөгаен, гаиләбездәге тәрбия, әти йогынтысыдыр бу дип уйлыйм. Ул безнең гадел кеше – әрсезлекне, кырын эшләрне җене сөйми. Хокук бозуларны күрсә, аның бик нык ачуы килә иде. Без үскәндә, төрле җинаятьләр, кыйнау-талаулар, гомумән, хокук бозулар күп була иде бит. Ә беренче чиратта кемне кыерсыталар? Әлбәттә, үзен яклый алмый торганнарга эләгә. Менә шуларга ярдәм итәсе килә иде. Кешене тәрбияләп үзгәртергә була. Берәү дә җинаятьче булып, бур-карак булып тумый. Вакытында ярдәм кулы сузу кирәк.

– Туры юлга басарга булышкан кешеләрдән рәхмәт сүзе ишеткәнегез бармы?

– Исерекләр, җәнҗалчылар һәм хокукны санга сукмаучылар арасында кайнагач, рәтле кеше очратмыйбыз дип уйлыйсыздыр инде. Шактый ишетәм мин андый яхшы сүзне. Хәтта җитәкчелеккә дә хат юллыйлар. Үз чиратында аннан рәсми тәстә рәхмәт кәгазе килә. Бу турыда күп сөйләү – тыйнаксызлык, сез сорагач кына бер-икесен әйтеп үтим. Беренче елны эшләгәндә беренче тапкыр ишеткән рәхмәт сүзен әле дә онытмыйм. Бер әби участокка елап килеп керде. Базарда мең сумын алдап алганнар. Барып тикшереп карагач, сатучы кайтарырга мәҗбүр булды. Кемгә ничектер, пенсионер әби өчен зур акча иде ул. Җитмәсә акча кысылган кризис елы да иде. Әбинең сөенгәнен күргәч, үзем дә куандым, әлбәттә. Аннары сигез балалы бер үзбәк кешесенә ярдәм иттем. Оланнарын балалар бакчасына урнаштырырга, яше җиткәннәрен мәктәпкә укырга кертергә кирәк бит. Дәүләт тарафыннан күрсәтелә торган социаль ярдәмне алу өчен «Вид на жительство» дигән документ алудан башларга кирәк иде аңа. Казанда туып-үсмәгән. Нинди кәгазьләр таләп ителүен дә, нинди оешмаларга йөрергә кирәклеген дә белми бу. Мин аны җитәкләп йөрттем һәм чагыштырмача тиз арада тиешле документларын җыйдык.

– Сүзебезне шушында тәмамларга да булыр иде, ашыгасыз да... Әмма күрәм, сезне көткән иптәшләрегезнең һәрберсенең бил каешында пистолет кобурасы эленгән. Иптәш майор, үзегез эшләгән вакытта берәр тапкыр корал кулланырга туры килдеме?

– Юк. Корал егетләргә үз-үзләрен яклау өчен бирелә. Егетләр эшне андый кискенлеккә җиткерергә тиеш түгел. Полиция инспекторы ул – профессионал, ул кискен хәлне дә чиккә җиткермичә алдан туктата белергә тиеш. Әйтәм бит, үземнең эшләү вакытымда төрле җәнҗаллар күрергә туры килде миңа, әмма аларны якалашмыйча тыныч кына хәл итә алдык.

Әңгәмәдәш – **Ильяс САЛИХҖАН.**

Безнекеләр дә туп тибә

Журналистлар футбол турында язып кына калмый, үзләре дә туп тибә белә. 23 июнь көнне Россиянең бер төркем каләм иясе Мексика уенчыларына каршы чыкты.

tatar-inform.ru

Матч башланырга сәгать ярым вакыт бар әле. «Буревестник» бассейны футбол мәйданы буп-буш. Ара-тирә физкультурадан «койрыкларын» ябучы студентлар гына чабып йөри. Ә безнекеләрнең беренче номерда уйнаган команда капитаны Җәүдәт Абдуллин («Бизнес-онлайн») инде футбол кырын сыный. Ул республика каләм ияләренең мини-футбол командасы капитаны да әле. Кәефе яхшылардан түгел, «мөгаен, җиңелербез», ди.

– Мексикалылар командасында профессиональ футболчылар бар. Алар – зур спорттан журналист яки комментатор эшчәнлегенә күчкән кешеләр. Инде берсенең фамилиясен күрдем, ул – Дөнья чемпионатларында уйнаган спортчы, – ди Җәүдәт Абдуллин.

Ул үзе дә футбол белән бары 18 яшендә генә шөгыльләнә башлаган. Бүген исә Казанның мини-футбол буенча иң өлкән һәм иң тәҗрибәле журналист-футболчысы.

– Язуы кызыкмы, әллә уйнавымы? – дип сорыйм үзеннән.

– Җиңсәң, әлбәттә, уйнавы кызыграк. Ләкин аның икенче ягы бар – команданы җыя белергә кирәк. Үзегез беләсез, без барыбыз да эш кешесе, гаиләбез бар. Бүген менә ике яхшы футболчыбыз уйный алмады.

– Спорт журналисты үзе спорт белән шөгыльләнергә тиеш дип уйлыйсызмы?

– Әлбәттә, тиеш! Монда нечкәлекләрне белү мөһим. Кайвакыт үзләрен профессионал дип санаган журналистлар, футболчы сызланып егылса, «кылана», «яхшы актер» дип сүгә башлый. Янәсе, елыйелый да ике минуттан берни булмагандай уйный. Минем үземнең дә шундый хәлдә калган бар. Кулга типтеләр, ләкин уен барганда, син авыртуны сизмисең, башта гына авыртып ала. Канда адреналин күчле бит. Ә менә матч беткәч, егыласың инде. Икенче көнне клавиатурадан хәреф җыя алмаган көннәр дә булды. Спортны сыра чөмереп кенә күзәткән кеше аңламый моны, – ди журналист.

Тора-бара башкалар да җыелды. Команданың тренеры Советлар Союзы футболчысы, ярымсакчы Евгений Ловчев та күренде. Беренче голны безнекеләр кертте. Алмаз Гафиятовның («Яңа Гасыр» каналы) пасыннан соң тупны Артур Мухин (ТР Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы) кертте.

Мексикалылар матч башланыр алдыннан гына килде. Бер түгәрәккә басып, нәрсәдер озак сөйләште. «Күптәннән футбол уйныйсызмы?» дигән сорауга да, «Беренче тапкыр», – дип серле елмайды араларыннан берсе.

Ләкин чит ил егетләре таштан яралган булып чыкты. Җаваплары тыйнак булса да, футбол кырында үзләрен бик иркен тоттылар. Капкачылары Мексика җыелмасының элеккеге уенчысы Освальдо Санчес булуы да ышаныч өстәгәндер үзләренә. Хәтта коеп яуган яңгыр да журналистларны туктата алмады. Нәтиҗәдә мексикалылар ике гол кертте. Хисап 1:2 безнең файдага.

Конфедерацияләр Кубогы кысаларында журналистлар арасында узган беренче дуслык матчын кунак команда аеруча да ошатты. Алар алга таба башка ил журналистлары белән дә көч сынашмакчы.

Алисә САБИРОВА.

→ **Теманың дәвамы 8нче биттә.**

Телефон аша дәвалыйлар

СӘЛАМӘТЛЕК

Табиб кайда гына булса да: эштәме, башка шәһәрдәме, чираттагы ялындамы, өендәме – консультацияне телефон аша бирә алачак. Телемедицина өлкәсенең камилләшүе, яңа технологияләр моңа мөмкинлек бирә. Республика клиник хастаханәсендә телефон, видео аша консультацияләр бирү инде дүрт ел гамәлдә. Былтыр телефон аша – 4500, видеоконференция ярдәмендә 600 консультация бирелгән.

tatar-inform.ru

Быелдан тагын бер яңалык: табибларның кесә телефонына урнаштырылган махсус Microsoft Lync кушымтасы ярдәмендә, кайда булуларына карамастан, белгечләр бер-берсе белән элемтәгә чыгып, район хастаханәләрендәге авыруларны дәвалау буенча киңәшләрен җиткерә алалар.

– 2009-2010 елларда Республика клиник хастаханәсе табиблары, «кукурузник» очкычына утырып, консультация бирер өчен ерак аралар уза торган булган. Бу шактый вакытны алган. Яңа технологияләр барлыкка килгәч, бер өстәл артына җыелып, район хастаханәләре белән элемтәгә чыга башладык. Тегеме яки бу диагнозга карата фикер алышулар, киңәшләр йә телефон, йә видеоконференция аша башкарыла иде. Хәзер әлеге система тагын да камилләште. Табиб кайда гына булса да, хәтта өеннән дә видеоконференциягә кушыла ала. Республика клиник хастаханәсенең территориясе бик зур. Табибка бер корпустан икенчесенә килеп җиту өчен вакыт кирәк, кайберләре авыруларны кабул итә. Кушымта ярдәмендә төп эштән аерылмыйча да киңәшләр бирергә була, – ди хастаханәдә ашыгыч кичектергесез консультатив махсуслашкан медицина ярдәме бүлеге җитәкчесе Айдар Фатыйхов.

Без килгән көнне дә Бөгелмә үзәк район хастаханәсеннән элемтәгә чыктылар. Бер авыруның берничә көн температурасы югары тора икән. Кулдан килгәннең барысын эшләгәннән соң да нәтиҗәсе булмагач, табиблар видеоконференция режимында Казан белгечләренә мөрәҗәгать иткәннәр. Видео ярдәмендә авыруның анализларын, кардиограмма сурәтләрен күрсәтеп тә була. Авыруның үзен дә күрергә мөмкин. Һәр реанимация бүлегендә камера куелган. Берьюлы берничә табиб фикер алыша ала. 40тан артык юнәлеш буенча медицина ярдәме күрсәтелә. Аеруча пульмонолог, кардиолог, хирург белгечлегенә ихтыяҗ зур икән. Әлеге системага 43 район хастаханәсе кушылган.

Көнөнә шундый бер-ике видео шалтыратулар кабул ителә. Республика клиник хастаханәсе – Россиядә бу өлкәдә ныклап эшләүче бердәнбер медицина учреждениесе.

Эльвира МОЗАФФАР.

БЕРЕНЧЕ АДЫМ

Үзәк район хастаханәсенә китерелгән авыру яки «ашыгыч ярдәм» хезмәте аша хастаханәгә эләккән пациенттан анализлар алына, тикшерү уздырыла. Авыруны дәвалау буенча сораулар туганда, җентекле тикшерү таләп ителгәндә район белгечләре Республика клиник хастаханәсенең ашыгыч кичектергесез консультатив махсуслашкан медицина ярдәме бүлегенә телефон аша шалтыратып, видеоконференциягә заказ бирә.

ИКЕНЧЕ АДЫМ

Ашыгыч кичектергесез консультатив махсуслашкан медицина ярдәме бүлегендә берничә табиб авыруның анализларын җентекләп тикшерә, район табибларына авыруны дәвалау буенча киңәшләр бирә, тәгәл диагноз куя. Кирәк булганда вертолет, реанимобиль белән авыруны барып алу да каралган. Казан табибларының Мәскәү белгечләренә мөрәҗәгать итү мөмкинлеге дә бар.

Хатын-кызлар бушлай тикшерү узды

Онкологлар мәгълүматлары буенча, күкрәк бизе яман шеше хатын-кызлардагы яман шешләр арасында беренче урынны алып тора.

Казанның «МЕГА» сәүдә үзәгендә барлык хатын-кызларга бушлай онколог-маммолог консультациясе алу, күкрәк бизләре тикшерүгә узу мөмкинлеге тудырылган иде. Әлеге чара «Казан күкрәк яман шешенә каршы» акциясе кысаларында узды.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгы матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, мондый акцияләр даими уздырыла.

– Республиканың тәҗрибәле онколог-маммологлары Түбән Кама, Чаллы, Әлмәттә хатын-кызларны тикшергән. Шик туган очракта, аларны, ныклап тикшерену өчен, Республика клиник онкология диспансерына җибәрәләр, – ди Республика клиник онкологик диспансерының медицина буенча баш табиб урынбасары Луиза Карпенко.

Кызганыч, яман шеш беренчел стадияләрендә үзен сиздерми. Шуңа да, тикшеренмичә, шешне ачыклау авыр. Акция кысаларында уздырылган сыйфатлы диагностика исә яман шешне башлангыч стадиядә ачыкларга мөмкинлек бирә. Луиза Карпенко әйтүенчә,

Онкологлар әйтүенчә, күкрәк рагы хатын-кызлардагы барлык яман шешләр арасында беренче урынны алып тора. Ел саен Россиядә 50 меңнән артык күкрәк яман шеше ачыклана.

биш-алты ел элек Россиядәге хатын-кызларның 63 проценты хастаханәгә яман шешнең соңгы стадиясендә генә мөрәҗәгать иткән. Хәзер исә 58 процент хатын-кызларда авыру башлангыч стадиядә беленә. «МЕГА» сәүдә үзәгендә узган акциядә 615 хатын-кыз катнашкан.

СОРАУ-ҖАВАП

18 яшькә кадәр инвалид баланы караган өчен дәүләттән нинди түләүләр каралган?

Айназ Сафина, Казан.

18 яшькә кадәрге физик яктан мөмкинлеге чикле балаларны, тумыштан I группа инвалидларны караучы ата-аналарга һәм опекуннарга ай саен акчалата ярдәм каралган. Инвалид баланы караган өчен, ай саен әти-әнисенә 5500 сум түләнеп барачак. Авыру баланы караган тәрбиячегә 1200 сум биреләчәк.

– Бу хакта теркәлү урыны буенча пенсия бүлегенә мөрәҗәгать итеп, гариза тапшырырга кирәк. Түләүләр баланы тәрбияләгән вакыт аралыгы өчен биреләчәк, – ди Россия Пенсия фондының Татарстан бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин.

Инвалид баланы опекунлыкка алган кешегә, әти-әнигә, эшләгән очракта, бу акча түләнми. Шулай ук пенсионерларга да, эшсезлек буенча пособие алучыларга да әлеге түләүләр каралмаган.

Татарстанда 18 яшькә кадәрге физик яктан мөмкинлеге чикле сабыйларны һәм I группа инвалид балаларны караучылар 12,9 мең кеше исәпләнә. Аларның 9,1 меңе – әтиәниләр, 3,8 меңе – авыру балаларны опекунлыкка алучылар.

Инсульт вакытында

БИЛГЕЛӘРЕ

Кинәт хәлсезләнү, кул, аяклар ою. **Сөйләм аңлаешсыз булу.** **Битнең бер ягы икенчесенә охшамау, авыз кыйгаю.** **Предметлар күзгә ике булып күренү.**

НИШЛӘРГӘ?

1. Тиз арада ашыгыч медицина ярдәме хезмәтен чакыртырга кирәк.
2. Тел астына дүрт-алты глицин дару төймәсе куегыз.
3. Физик эш белән шөгыльләнмәскә, утырып яки ятып торсаң яхшырак.

ИСТӘ ТОТ: әгәр дә кешедә шушы билгеләр күзәтелсә, алар 10 минут эчендә бетеп, хәл яхшырса да, «Ашыгыч ярдәм» хезмәте чакыртырга кирәк. Болар барысы да инсульт алды билгеләре булырга мөмкин.

КЕШЕ ҺӘМ ВАТАН МӨНӘСӘБӘТЕ

«Шәһри Казан» газетасының 11, 18 май саннарында Марат Кәбировның «Туган ил тик бер генә...», «Ватан һәм ана...» дигән яшәешебезнең актуаль иҗтимагый-фәлсәфи, социаль якларын кыю, үткен бәян иткән язмалары күпләрне битараф калдырмагандыр.



КАЙТАВАЗ

Әлегә кадәр бу мөнәсәбәтне Ватан һәм ана белән янәшә куеп, ачык итеп аңлатып бирергә берәү дә җөрьәт итмәгән иде. Ә иң әһәмиятлесе, хикмәте һәм һич кенә дә көтелмәгәне – «Ә безнең Ватан бармы соң ул?» дигән нәтиҗәсе.

Күптән түгел «Таныш моңнар» әдәби-музыкаль клубында фронтовик-язучы, шагыйрь, прозаик, публицист, драматург Нәби Дәүли (1.06. 1910-18.05.1989) иҗатына багышланган кичә үткәрелде. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләү өчен миңа аның әсәрләрен генә түгел, каләмдәшләре Зәки Нури, Марсель Галиев, Шамил Маннаповның аның турында язганнары белән дә танышып чыгарга туры килде, аларны Марат Кәбиров фикерләре белән бәйләү җае да чыкты.

«Безнең Ватан бармы соң?» дигән сорауга ул заманда һәркем: «Әлбәттә, бар!» – дип кенә кистереп җавап бирергә мәҗбүр булгандыр. Шул исәптән дүрт яшеннән әнисез, бераздан әтисез дә калган, «балам» дип эндәшүче булмаган ятим малай Нәби дә.

Спас өязе (хәзерге Әлки районы) Иске Камка (Мәүләшә) авылыннан бәхет эзләп Кавказ якларына киткән үги атасы Ставрополь кырларында бер байның сарык көтүен көтә. Аннары ул, өч ятим баланы шул бай кулында калдырып, үз авылларына йорт-җирләрен сатарга дип кайтып китә дә, хатыны үлү сәбәпле, кире әйләнеп килми. Өч ятим бала байның өч туганы кулына килеп эләгә, аларның берсе – Нәбине Царицын янындагы Чапурин авылына алып китә.

Ниһаять, унбер яшьләрендә Нәбине балалар йортына урнаштыралар. Ул шунда һөнәргә, рәсем ясарга, җырларга өйрәнә, җидееллык белем ала, ФЗӨ мәктәбен тәмамлый. Аннан соң абыйсы янына Донбасска барып, паровоз ремонтлаучы булып эшкә урнаша. Шул елларда Донбасста татар шахтерлары өчен чыгарыла торган «Пролетар» исемле газетада беренче хәбәрләре, шигырьләре, очерклары басыла башлый.

Ике елдан соң ул, Винницада полковой мәктәп тәмамлап, старшина була, аннары 1935 елга кадәр Ерак Көнчыгышта чик буе сакчысы булып хезмәт итә.

Шул тормыш мәктәбен узганнан соң Казанга килә, яшьләр газетасында эшли, әдәби тормышка кушылып китә. Аның шигъри иҗаты редакторы Муса Җәлил булган «Октябрь баласы» журналында башлана.

1937-1941 елларда «Бәхет», «Ал чәчәк», Уйлар», «Кырык шигырь» исемле дүрт китабы нәшер ителә.

Бөек Ватан сугышы башлану белән, фронтка китә, озак та үтми, Орша янындагы авыр сугышларда фашистлар кулына әсирлеккә эләгә, 1945 елга кадәр үлем лагерьларында коточкыч газаплы көннәр кичерә.

1945 елның декабрендә Нәби Дәүли Казанга кайта, әмма аңа, әсирлектә булган кешегә, әдәбият, матбугат өлкәсендә эшләргә рөхсәт ителми, шуңа күрә 1956 елга кадәр төрле оешмаларда кара эшче, каравылчы, рәссам-бизәүче кебек әдәбияттан ерак торган хезмәт вазифаларын башкарырга туры килә. Сталинның вафатыннан соң әсирләргә карата булган кешелексез мөнәсәбәт үзгәргәч кенә, язганнарын бастыру мөмкинлеге туа.

Язучының «Яшәү белән үлем арасында» повесте (1958) һәм «Җимерелгән бастион» романы (1965) укучылар арасында аеруча зур популярлык казана.

Әсирлек газабын кичергән фронтовик-язучы Нәби Дәүлинең сугыштан соң туган илендә – Ватан-анасында «үги бала» сыйфатында яшәвенә кем гаепле дигән сорау куйсак: «Һәрхәлдә, үзе түгел бит инде, шушы ил гаепле!» – дип җавап бирергә туры килер иде.

Әлеге уңайдан Марсель Галиевнең моннан 12 ел элек «Казан утлары» журналында Нәби Дәүли турында язган «Яшәү белән үлем арасында» дигән мәкаләсендә әйтелгән кыю фикер белән таныштырып китү дә урынлы булыр. Ул болай дип яза: «Сугыш театрында командирларның хатасы аркасында яисә башка бер сәбәптән тулы армияләр чолганышта калырга мөмкин ләбаса. Солдатның монда ни гаебе бар? «Дошманга тереләй бирелмәскә!» дигән приказны ничек кабул итәргә? Сугыш өчен дип түгел, тыныч тормыш төзергә яратылган кешегә гомер бер генә бирелә. Ул яшәргә тиеш! Агач мылтык тотып сугышка кергән кешеләрнең сөйләгәннәрен ишеткәнем бар. Агач мылтыклыдан: «Тереләй бирелмәскә!» – дип ничек таләп итәсең? Үзе теләп бирелмәгән әсирләргә карата «илен саткан» дигән мөһер сугарга кемнең хакы бар?! «Яшәү белән үлем арасында» повесте бәхетле тәмамлана. «Чынлап та шулай булдымы?» дигән сорауга:

–Язганча булса икән... Ул минем хыялым иде... Ил чиген узгач, тагын тоткын булырмын, дип башыма да китермәгән идем. Себергә үк озатмадылар озатуын... Чәнечкеле киртәләр сузып, шпал ташып, үзебезгә үзебез лагерь төзедек. Хәл юк, ач-ялангач. Ике кеше берләшеп, шпалны җилкәгә саласың да, көч биреп, яңак белән терәп барасың. Менә бу шадра эзләр шул шпалдагы май кисеп кергәннән... Фиргавеннәр чорындагы коллар кебек, шпал күтәргән колонна чакрымнарга сузыла, – дип сөйләгән.

Казанга кайткач та эшкә урнаша алмый йөри, язган әсәрләрен беркайда да басмыйлар.

– Кич җитсә, җантимер килә. Черек күл буена алып китәләр дә төн буе аяк өсте тотып сорау алалар. Атналар буе шул хәл, йокысызлыктан тәмам исереп, аң бетә башлый. Тегендә... фашистларны күп күрдем, үз илеңдә күзеннән иман нуры качкан палачлар барлыгын белү икеләтә авыр иде, –дип искә алган ул.

Бөек Җиңүнең 30 еллыгы уңаеннан, ветеран-язучылар чәй мәҗлесенә җыелганнар иде. Арада күкрәк тулы орден-медальләләр бар. Барысы өч дистәгә якын өлкәннәр. Сыннары туры, йөзләре яшәреп киткән кебек. Бер-берсенең орден-медальләрен тотып-тотып карыйлар. Арада бердәнбер Нәби аганың гына түшендә берни дә юк, – дип тә искә алган автор, аны кызганып.

Хәер, ни гаҗәп, орден-медальләре генә түгел, фронтовик-язучы Нәби Дәүлинең әдәби бүләкләре, исем-дәрәҗәләре дә булмаган икән. Югыйсә, зур популярлык казанган «Яшәү белән үлем арасында» повесте 1958 елда ук, вафатына кадәр 40 ел элек басылып чыккан, аннан соң күпме әсәрләре дөнья күргән! Монысына Сталин режимы гаепле түгел бит инде! Күрәсең, газап-әрнүләргә, гаделсез кимсетелүләргә фашистлар, илдәге тикшерүче-палачлардан гына түгел, хәтта каләмдәшләре-язучылар тарафыннан да дучар ителгән. Ничек соң араларында яу кырындагы кебек кыюлык, уяулык күрсәтерлек бер генә каләм әһеле дә булмаган? Нинди ваемсызлык, битарафлык, гаделсезлек! Ә бәлки, куркаклыктыр? Азмыни үз күләгәләреннән үзләре куркып, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүчеләр.

Хәер, кызганыч, мондый мөнәсәбәт бүген дә дәвам итә: шундый хәлгә калдырылган язучылар байтак, шул ук вакытта мөмкинлекләрдән төрле юллар белән файдаланып, кәбестә күк катлы-катлы, чегән күлмәгедәй өсте-өстенә исем, дан-дәрәҗә җыючылар саны арта бара.

«Шулай да, үлем белән яшәү арасында калган чакларында да Әҗәлне җиңә алган, «атказанган» яисә «лауреат» шикелле купшы исемнәр алып бозылмаган Нәби Дәүли үз иҗатының халык күңелендә каласына тирәннән ышана, шуңардан яшәү көче, җан тынычлыгы таба, очрашуларның дәвамлы булачагына өмет итә иде. Инде аның бу өметле уйлары-хыяллары җан җылысын саклаучы әсәрләрендә, радио аша әледән-әле яңгырап торган моңлы-аһәңле җырларында гына калды... Нәби Дәүли иҗаты турында әтрафлы хезмәтләр юк та бугай. Нәби абый исән вакытта моңа үзе дә борчыла торган иде. Кыскасы, милләтебезнең талантлы улы, һәрьяклап кызыклы шәхесе калдырган рухи хәзинә җентекле өйрәнүчесен һәм халкыбызга җиткерүчесен көтә», – дип язган Шамил Маннапов «Казан утлары» журналының 2000 елгы 6нчы санында.

Марат Кәбировның «Туган ил тик бер генә...» дигән язмасындагыча: «Безнең илдә бабасы яки әбисе яуда катнашмаган, яки үлеп калмаган бер генә гаилә дә юк диярлек. Һәм андый гаиләләрнең берсенә дә җиңүче дәүләт әллә ни игелек күрсәтә алмады. Бер сүз белән әйткәндә, яуда үлеп калган гади солдат гаиләләренә бу Җиңү бернинди кадер-хөрмәт китермәде. Беркайчан да».

Аерым кешегә генә түгел, бик күп милләтләргә, шул исәптән безгә карата да шулай булды. Югыйсә татарлар, халык санына бүлеп исәпләгәндә, илдә Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган милләтләр арасында беренче урында тора. Шунысы да мәгълүм: Гитлер үзенең бер чыгышында СССРда яшәүче халыклардан татарларны гына мактап телгә ала. Шуннан соң Сталин татарларга ул исемне бирүне тыя: аның урынына Михаил Калинин «Батырлык медале»н бирү турындагы Указга гына кул куя. Юкса, ул исемне алучы татар каһарманнары тагын да күбрәк булган булыр иде. Рейхстагка Җиңү байрагын татар егете Гази Заһитов элә, ә Сталин аның данын Егоров белән Кантариягә бирә. Гитлерның империя канцеляриясен дә Идрис Гомәров полкы ала. Дошман амбразурасын да күкрәге белән беренче булып ятимнәр йортында тәрбияләнгән Шакирҗан Мөхәммәтҗанов (Александр Матросов) каплый. Исхак Әхмәров та – дошман тырнагына эләкмәгән бердәнбер атаклы татар разведчигы. Ул, Япониянең СССРга һөҗүм итүен икенче якка борып җибәреп, АКШның сугышка керүенә сәбәпче була.

Шуларның «әҗере» итеп дигәндәй, бүген республика үзәккә 70-80 процент салым түләп яшәргә мәҗбүр ителгән, ә аның байтагын коррупция, офшора, казна караклары бүлешә дип әйтелә.

Фронтовик-язучы Нәби Дәүли дә үз Ватанына хезмәт итеп, сугышып, көрәшеп, иҗат итеп яши, әмма туган илендә кадер-хөрмәт, рәхәт күрми вафат була. Бу очракта Кеше һәм Ватан мөнәсәбәте менә шуннан гыйбарәт!

Хәнәфи БӘДИГЫЙ.

КОНФЕДЕРАЦИЯЛӘР КУБОГЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Мексика егетләре

Россия җыелмасын елатты

Конфедерацияләр Кубогында «А» төркемендә ярымфиналга чыккан командалар билгеле булды: 28 июнь көнне «Казан-Арена» стадионы Португалия белән Чили футболчыларын каршы алачак. Безнекеләр исә шимбә көнне мексикалыларга 1:2 исәбе белән оттырды.

Алисә САБИРОВА

ӨМЕТ СҮНДЕ

Уен бик киеренке башланды. Җиңүне берсенең дә кулдан ычкындырасы килми шул. Беренче минутлардан ук Россия җыелмасы һөҗүмгә кереште, ләкин Португалия белән булган уеннан әллә ни ерак китмәделәр кебек. Көндәшнең капкасына барып җитсәләр дә, туп, капка эченә кермичә, кыек китә торды. Күңелне, тагын җиңелербез инде, дигән шом баса. Әчтән генә «кәкре аяклар» дип сүгенеп тә куясың. Аеруча да Юрий Жирковка ачу килде. Шундый мөмкинлекне ычкындырды бит. Икенче таймда бөтенләй, команданың канатын сындырып, уеннан ук алып атылар үзен. Безнекеләр кыек аткан саен, мексикалыларның бөдрә чәчле капкачыларының (Гильермо Очоа) йөзендә елмаю балкый. Ул да әчтән генә «кәкре аяклар» дип көлә сыман.

Россия җыелмасының капкага җитәрәк ике тапкыр егылуы да җанатарларга ошамады. Беренчесен хөкемдар җиңел генә уздырды. Икенчесен исә зал, күтәрелеп, видеодан кире тикшертте. Чыннан да, Мексика уенчысы безнекен эткән булып чыкты, тик хөкемдар моны «штраф» салырлык хокук бозу дип санамады. Уен дәвам итте.

Безнекеләр 25нче минутта көндәш капкасына туп кертүгә иреште. Гол авторы – Александр Самедов. Бу тупка озак сөенә алмадык, биш минуттан мексикалылар җавап кайтарды. Икенче гол да Россия капкасына керде. Монысын, безнең бәхеткә, «офсайд» дип игълан иттеләр. Димәк, әле җиңүгә мөмкинлек бар, сыгылмаска гына кирәк.

Мексикалыларның ачуларын үз капкаларына керткән гол кабартса, тагын да көчлерәк уйнарга этәрсә, безнекеләр төшенкелеккә бирештеләр. Инде чираттагы – Игорь Акинфеев белән Виктор Васин туктата алмаган мәгънәсез голдан соң команда бөтенләй таралды. Икенче таймда Россия җыелмасына «сары карточка»лар да күп яуды. Кудряшов, Васин «саргайды».

Россия – Португалия матчы җанатарларда «әһ, бәлки!» дигән өмет чаткысы уяткан иде. Бүген халык шул өмет белән, бәйрәмгә әзерләнгән кебек, Россия флагы төсләренә ыспай гына киенеп килгән иде, ләкин матчтан соң алкышлар ишетелмәде. Уен бетүгә, халык, бердәм булып, урыннан купты да китеп барды. Берән-сәрән калган җанатарлар гына: «Россия», – дип кычкырган булды, тик гомуми рухны бу инде үзгәртә алмады.

«РОССИЯ – КӨЧЛЕ КОМАНДА, КӨЧЛЕ КӨНДӘШ»

Спортчыларның да кәефе кырылган иде. Һөҗүмче Фёдор Смолов стадионда ук күз яшьләрен тыя алмады. Җанатарларга рәхмәтен белдерде.

– Уен португалиялеләр белән көрәшкән кебек артык авыр булмады, башта бик җайлы барды. Кулдан ычкындырган мөмкинлекләр күп булды. Хөкемдар безнең бер «пенальти»ны санамады. Мин капкага тибәргә җыенганда, берсе этеп екты, – ди Фёдор Смолов.

Акинфеев бик авыр хәлдә калды. Журналистларның: «Хәзер сезне тагын «чәйнәрләр» инде», – дигән сүзләренә:

– Миңа хәзер асылынырга мы инде? – дип җавап бирде.

Россия капкасына иң матур гол керткән Ирвинг Лосано бу уенда иң яхшы футболчы дип билгеләнде.

– Россия көчле команда, көчле көндәш булып чыкты. Алар бик кырыс уйный. Мин башта тупның еракка барамы-юкмы икәнен карадым. Аның белән капкага кадәр барып җитеп булганлыгын аңлагач, артыннан чаптым, – дип сөйләде ул матчтан соң.

Россия җыелмасы тренеры Станислав Черчесов уеннан соң иң тыныч кеше булып күренде. Әйтерсең ул җиңелүләренә гаҗәпләнмәгән дә. Журналистлар исә инде Черчесовны «отставка»га җибәрергә әзер иде, хәтта бер кыю: «Мондый уеннан соң китәсездер инде?» –дип тә сорады. Моңа тренерның җавабы кыска булды.

– Мин бик рәхәтләнеп эшләдем, эшлим һәм эшләячәкмен, – дип кырт кисте ул. – Хәзер уенга нәтиҗәләр ясарга кирәк. Безнең 75 процент футболчының мондый турнирда катнашканы юк әле. Мин уеннан да, футболчылардан да канәгать. Спорт – спорт инде ул, тормыш дәвам итә.

Мексика тренеры Хуан Карлос Осорио, бүген лаеклы көндәшләр белән уйнадык, ди.

– Бу авыр уен булды. Россия көчле һөҗүм итә. Аеруча да 9, 17, 18 номерлы уенчылары. (Федор Смолов, Александр Головин, Юрий Жирков. – **Авт.**). Россиялеләрнең артка юллары юк иде, бары җиңү. Без исә, нинди көндәш булуга карамастан, яхшы уйнарга тиеш икәнебезне аңладык. Мин 1:3 булыр дип көткән идем, – диде Хуан Карлос Осорио.

«ФУТБОЛЧЫ БУЛГАЧ, МАШИНА АЛАМ»

Җанатарларның әле озак «Казан-Арена» тирәсендә бәхәсләшкәнен, нидер кызып-кызып сөйләшкәннәрен ишетеп булды. Кемдер Акинфеевны сүгә. «Картайды, яшьләргә урын бирсен», – диләр. Кемдер, киресенчә, яклый. Безнең телгә хас булмаган акцент белән сөйләшкән җанатарларны да ишетеп була. Болары Сербиядән килгән икән. «Бүген кем өчен җан аттыгыз?» – дим үзләренә.

– Россия өчен! Без бит тугандаш халык. Менә сезнең җыелмага көч бирү өчен килдек. Безнең футбол да инде сезнеке белән бер чама. Мондa футболчыларны да, тренерны да гаепләп булмый. Футболга карашны тамырдан үзгәртергә кирәк. Спортта сәясәткә урын юк. Бердәмлек тоймадым мин. Һәр кеше үзе өчен генә уйный дигән карарга килдем, – ди Драган Спасоевич.

Чыннан да, бүген футбол зур акчалар әйләнә торган «майлы калҗа»га әверелде. Әле футбол тубы тибә генә башлаган малайлар, инде профессиональ спортка килгәч, нинди машиналар алачагы турында тәгаен белә. Конфедерацияләр Кубогы матчлары ачылышында футболчыларны җитәкләп стадионга чыккан берничә малай белән сөйләшеп тордым. Җиде-сигез яшьләр тирәсендәге Кирилл белән Тимур «Рубин» клубының балалар төркемендә шөгыльләнә.

– Үскәч кем булырга телисез, егетләр?

– Футболчы инде, – ди Тимур.

– «Рубин» өчен уйныйсым килә. Максатым – Россия җыелмасына эләгү, – ди Кирилл.

– Ә ни өчен футболчы?

– Футболчылар акчаны күп эшли. Машина сатып аласым килә – Лексус… Мерседес булса да ярый. Лада Калина гына булмасын, – ди Кирилл.

– Казан һәрвакыт безнең өметләрне аклады. Ул, лаеклы рәвештә, илнең спорт башкаласы булып тора. Бирегә зур спорт чаралары оештырыла. Монда аны югары дәрәҗәдә үткәрә дә беләләр, – диде Россия Федерациясе вице-премьеры Виталий Мутко.

Шәһри Казан

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)

www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

Бу санның тиражы – 1580. Гомуми тираж – 5955.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 729. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+

Сатудагы бәясе ирекле

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562-50-12,
факс: (843) 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы